ГЛАВА МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**Карар** **Постановление**

№ 220 от «25» 10 2024 г.

Район Башлыгының 2015 елның 3 июнендәге 049 нчы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында (07.05.2020 ел, №032; 20.07.2022 ел, № 133; 16.12.2022 ел, № 242, 15.09.2023 ел, № 145 карарлардагы үзгәрешләр белән)

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» 2010 елның 30 июлендәге № 60-ТРЗ номерлы, «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 26 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары нигезендә карар бирәм:

1. Мамадыш муниципаль районы Башлыгының 2015 елның 3 июнендәге «Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органнарының административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеген билгеләү турында» 049 нчы карары (алаг таба- Карар) белән расланган Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Карарга Татарстан Республикасы Административ хокук бозулар турында кодексының $3.15^1$статьясын өстәргә (кушымта нигезендә);

1.2. 3.2 статьяның исемен Карарда түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Урам сәүдәсен һәм халыкның күңел ачуына бәйле булган хезмәтләр күрсәтүне оештыру тәртибен бозу»;

2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы вазифаларын башкаручы Р.Р. Сәмигуллин

000241

Муниципаль район Башлыгының
«25» 10 2024 ел,
№220 карарына
кушымта

| статья № | статьяның эчтәлеге | Протоколлар төзү вәкаләтләре йөкләнгән җирле үзидарә органы | Вазифаи затның вазифасы |
|---|---|---|---|
| Ст.3.15[1] | Җәмәгать урыннарында товарларны һәм хезмәт күрсәтүләрне көчләп тагу | Исполнительный комитет муниципального района | - -Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының хокук эше бүлеге баш белгече (җәмәгать тәртибен саклауны һәм җәмәгать куркынычсызлыгын оештыру буенча)<br>-Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының хокук эше бүлегенең әйдәүче белгече (торак секторда хокук бозуларны профилактикалау һәм индивидуаль профилактик йогынты чараларын куллану буенча инспектор),<br>- Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге җитәкчесе<br>-Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге баш белгече |

Муниципаль район Советы аппараты җитәкчесе В.Н.Фәизов